**СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**СОВЕТЫ**

Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы, Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru


**Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«21» октябрь 2019 ел** **№ 129**

**Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясына яраклаштырып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кенәр авыл җирлеге башкарма комитетының «Референдум үткәрүдә инициатива күрсәтү турында» 2019 елның 17 октябрендәге 104 номерлы карары, Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының «Референдум үткәрүдә инициатива күрсәтү турында» 2019 елның 17 октябрендәге 128 номерлы карары нигезендә Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы **КАРАР** бирде:

1. 2019 елның 08 декабренә Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
"2020 елда сез Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, 1 нче Төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, балачак инвалидларыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, Чернобыль АЭСдәге аварияне бетерүдә катнашучылардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле

әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшләре алып бару:

- урам-юл катламы нигезен салып вак таш түшәү:

**Яңа Кенәр авылы** - Урак Чүкеч урамы (250 м), Ленин урамы (150 м), Татарстан урамы (200 м), Р. Төхвәтуллин ур. (500 м), Октябрь урамы (100 м), Фатхуллин урамы (150 м),1 Май ур. (200 м), Совет урамы (150 м), Куйбышев урамы (200 м);

**Яңа Ашыт** авылы-Вахитов урамы (100 м);

**Шурабаш** авылы-Чапаев урамы (250 м), Гагарин урамы (101 м);

**Шура авылы**-Һ. Такташ урамы (50 м), Яңа Алиф ур. (159 м);

**Байкал авылы**- Тукай урамы (153 м), Ленин урамы (50 м);

**Яңа Сәрдә авылы**-Һ. Такташ урамы (104 м);

**Сөрде авылы**-Совет урамы(50 м), Киров урамы(100 м),Урман урамы(50м)

**Югары Оры авылы**-Киров урамы (168 м);

**Түбән Оры авылы**-Г. Салихов урамы (50м.), Җиңү урамы (50 м),Г.Гафия-Г. Гафиятуллин урамы (50 м), Тукай урамы (63 м);

**Кызыл Яр авылы**- Нариман урамы (60 м), Киров урамы (38 м), Тукай урамы (40 м)

2) Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Сөрде авылында балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм халык күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: ТР, Арча районы, Үрнәк бистәсе, Урман урамы, 44а йорты; Татарстан Республикасы, Арча районы, Казанбаш авылы, Киров урамы, 49 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Урта Пошалым авылы, Вахитов урамы, 15 йорт.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Фәхретдинов Р.Ә.

СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ